СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**08.06.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 195**

Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларны үзгәртү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, дәүләт, республика, муниципаль район һәм (яисә) иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында истәлекне саклап калу максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларны үзгәртү тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карар кабул ителгән көннән ике ай эчендә түбәндәгеләр тапшырыла:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау буенча комиссия составын төзергә һәм расларга;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карау буенча комиссия хакында нигезләмәне эшләргә һәм расларга;
- гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү турында гаризаларның (үтенечнамәләрнең) формаларын эшләргә һәм расларга.

3. Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү мәсьәләләрен хәл иткәндә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карау буенча комиссия белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү тәртибе турындагы актларны бастырганда, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында, әлеге карарның 1 пунктында расланган актта каралган нигезләмәләргә таянып эш итәргә;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында булдырылган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау буенча комиссия белән муниципалитетара килешүләр нигезендә элемтә оештырырга.

5. Юридик затларга, оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгаларның исемнәрен бирү мәсьәләләрен хәл иткәндә, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр (оешмалар) өчен, истәлекләрен мәңгеләштерү күздә тотылган объектларны сайлау өлешендә, әлеге карарның 1 пункты белән расланган актлар критерийларына, шулай ук аларга күрсәтелгән исемнәрне бирү кагыйдәләренә таянырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар, әлеге карарның 1 пункты белән расланган гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдән, шулай ук әлеге карарның 3, 4, 5 пунктларыннан тыш, массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү тәртибе турындагы нигезләмә, шулай ук әлеге карарның 3, 4, 5 пунктлары массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән соң 60 көн узгач үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск
муниципаль районы
Советының 2017 елның
08 июнендәге 195
номерлы карарына
кушымта

**Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларны үзгәртү тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларны үзгәртү тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә, Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба – муниципаль берәмлек) тарафыннан төзелгән муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) күрсәтелгән затларның исемнәрен бирү юлы белән гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү кагыйдәләрен һәм тәртибен билгели.

1.2. Нигезләмә түбәндәге мәсьәләләрне җайга салмый:

гражданнар законнары таләпләре нигезендә муниципаль предприятиеләргә аларны төзегәндә исемнәр бирүне;

Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирүне;

күренекле галимнәрнең хәтерен мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирүне;

күренекле гражданнар, оешмалар, тарихи вакыйгалар исемнәрен бирү белән бәйле муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр (оешмалар) биналарында мемориаль (истәлекле) такталар урнаштыруны

1.3. Сәяси репрессия корбаннары дип танылган затларның хәтерен мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исем бирү мәсьәләләрен җайга салганда «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1номерлы Россия Федерациясе Законы белән билгеләнгән нигезләмәләр исәпкә алына

1.4. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү дәүләт, республика, муниципаль район һәм (яисә) иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында хәтерне саклап калу максатларында гамәлгә ашырыла.

1.5. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирелә:

дәүләт һәм (яки) җәмгыять, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы үсешенә керткән өлеше рәсми рәвештә танылган яисә

гомумтанылган дәүләт, сәяси һәм җәмәгать эшлеклеләре, башка гражданнар,оешмалар (тарихи вакыйгалар)

икътисад (шул исәптән сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм башка өлкәләрне) , сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, сәнгать, мәгариф һәм белем бирү, социаль яклау, үсеп килүче буынны тәрбияләү, муниципаль берәмлектә хәйрия эшчәнлеге үсешенә зур өлеш керткән күренекле гражданнар;

үз эшчәнлекләре, казанышлары белән муниципаль берәмлек составындагы муниципаль берәмлеккә, җирлеккә (торак пунктка) башкача файда китергән яисә муниципаль берәмлек алдындагы башка казанышлары булган күренекле гражданнар;

хезмәте белән, иҗтимагый, һөнәри һәм башка эшчәнлеге муниципаль берәмлек чикләреннән тыш абруй һәм җәмәгатьчелек тарафыннан танылу яулаган муниципаль берәмлектә туып-үскән шәхесләр;

муниципаль берәмлек үсешенә сизелерлек йогынты ясаган күренекле тарихи вакыйгалар;

муниципаль берәмлек үсешенә зур өлеш керткән, аның абруен күтәрүче күренекле оешмалар.

1.6. Муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү турында карар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары (алга таба – карар, Башкарма комитет) яки Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарәсенең башка органының алар гамәлгә куйган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата күрсәтмә акты белән кабул ителә.

Муниципаль предприятиегә яисә учреждениегә исем бирүдән баш тарту Башкарма комитет күрсәтмәсе (алга таба - боерык) белән рәсмиләштерелә.

1.7. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исем бирү чараларын финанслау муниципаль предприятие яки учреждениегә исем бирү турында үтенечнамә юллаган инициатор акчасы хисабына башкарыла.

1.8. Муниципаль предприятиегә яисә учреждениегә исем бирү муниципаль берәмлектә мөһим вакыйга булып тора, шуңа бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары һәм җәмәгатьчелек катнашында тантаналы шартларда чаралар оештырыла, матбугатта (башка массакүләм мәгълүмат чаралары) яктыртыла.

1.9. Кабул ителгән карарлар Зеленодольск муниципаль районы Уставында каралган тәртиптә рәсми басылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 2. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү кагыйдәләре

2.1. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү хәзерге рус әдәби теле нормаларын үтәп башкарылырга тиеш (татар телендә исемнәр биргәндә - татар әдәби теле нормаларын үтәп).

2.2. Ике яки берничә муниципаль предприятиегә яки учреждениеләргә бер үк исем бирү рөхсәт ителми.

2.3. Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең исемнәрен үзгәртү ике яки аннан да күбрәк муниципаль предприятиеләргә яки учреждениеләргә элек бер үк шәхесләрнең, оешмаларның һәм тарихи вакыйгаларның исемнәре бирелгән очракта, бу хуҗалык яки башка эшчәнлекне

гамәлгә ашыруны кыенлаштырганда, шулай ук аерым муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә элек бирелгән (тарихи) исемнәрне кайтару максатыннан рөхсәт ителә.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, башка затларның исемнәре, күрсәтелгән затлар үлгәннән соң , муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә бирелә.

2.5. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү турында карар кабул иткәндә, Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән затларның якын туганнары (алар булганда) муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү юлы белән истәлекне мәңгеләштерү мөмкинлеге турында фикере исәпкә алына.

2.6. Вакыйганың яки исемен мәңгеләштерү тәкъдим ителгән кешенең әһәмиятен объектив бәяләү максатыннан, предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү:

Исеме мәңгеләштерелә торган зат вафат булганнан соң 5 ел үткәч;

исеменә лаек булган вакыйгадан соң 10 ел узгач.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларындагы нигезләмәләр Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе хезмәт Геройлары, Слава ордены белән бүләкләнгән гражданнар, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнар, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнгән гражданнар исемнәрен бирү очракларына һәм учреждениеләргә кагылмый.

2.7. Муниципаль предприятие яки учреждениегә исеме бирү күздә тотылган гражданның туганнары күрсәтелгән исем бирү инициативасы белән чыга алмый.

## 3. Карарлар (боерыклар) кабул итү тәртибе

3.1. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исем бирү инициаторлары булып дәүләт хакимияте органнары, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, предприятие, учреждение, оешмаларның хезмәт коллективлары һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук 15 кешедән ким булмаган гражданнарның инициатив төркемнәре (алга таба - инициаторлар) чыга ала. Инициатив төркемдә катнашучылар санының кимендә яртысы муниципаль берәмлек халкы булырга тиеш, аның составына Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән затлар керергә тиеш түгел.

3.2. Инициаторлар Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыралар:

1) инициатор турында белешмәне үз эченә алган, муниципаль предприятиегә яки учреждениегә әлеге исем бирүне нигезләгән һәм моның белән бәйле чараларны финанслау чыганаклары турында тәкъдимнәр бәян ителгән гариза

яки үтенечнамә (юридик затлар өчен - юридик зат исеме, юридик адрес һәм элемтә телефоны; физик затлар өчен - гражданнарның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, яшәү урыны адреслары, паспорт белешмәләре, контакт телефоннары);

2) вакыйганың дөреслеген яисә исеме мәңгеләштерелә торган затның (оешманың) казанышларының дөреслеген раслаучы архив яки башка документларның күчермәләре;

3) муниципаль предприятие яисә исеме бирелә торган учреждение турында мәгълүмат булган документлар шул исәптән:

гамәлдәге исеме, урнашу урыны (адресы), юридик адресы;

җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә өчен мәгълүматлары;

предприятиенең (учреждениенең) күренекле зат, оешма яисә тарихи вакыйга исеменә лаек булуын раслый торган белешмәләр;

4) исем бирү күздә тотылган муниципаль предприятие (учреждение, оешма) җитәкчесенең инициатива белән килешмәү яисә ризалык бирүе турында язма рәвештә (ирекле формада) белдерелгән фикере;

5) исем бирү күздә тотылган муниципаль предприятиене (учреждениене, оешманы) гамәлгә куючының (милекченең) вәкаләтле вәкиленең, аңа исем бирү инициативасы белән килешмәү яисә ризалык бирүен белдергән язма рәвештә (ирекле формада) фикере.

3.3. Башкарма комитет кергән гаризаларны (үтенечләрне) һәм өстәмә материалларны теркәүне һәм исәпкә алуны гамәлгә ашыра һәм теркәлгәннән соң 5 эш көне эчендә әлеге документларны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясенә (алга таба - Комиссия) җибәрә.

3.4. Башкарма комитетка тулы булмаган документлар кергәндә яки документлар Нигезләмәнең 3.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, күрсәтелгән документлар инициаторларга җитешсезлекләрне бетерү тәкъдиме белән кире кайтарыла. Инициатор күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң гариза (үтенечнамә) белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Документлар шулай ук Нигезләмәнең 3.10 пунктындагы икенче абзацында каралган нигезләрдә инициаторга кире кайтарыла.

3.5. Комиссия Башкарма комитет каршында төзелә.

3.5.1. Комиссиянең составы һәм Комиссия эшчәнлеген регламентлаучы нигезләмә Башкарма комитет тарафыннан раслана.

3.5.2. Комиссия составының кимендә өчтән бер өлешен вазыйфаи затлар, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре булмаган җәмәгатьчелек вәкилләре тәшкил итәргә тиеш.

3.5.3. Комиссия утырышлары эшендә инициаторлар (инициаторлар вәкилләре) катнашу мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

3.5.4. Комиссиянең беренче утырышы Башкарма комитетта гариза (үтенечнамә) теркәлгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә. Комиссиянең йомгаклау утырышы Башкарма комитетта гариза (үтенечнамә) теркәлгәннән соң 25 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә. Йомгаклау карары Комиссиянең беренче утырышы барышында кабул ителергә мөмкин. Кворумны тәэмин итү йомгаклау карары кабул ителә торган утырышта таләп ителә.

3.5.5. Кирәк булган очракта, Комиссия Башкарма комитетның үз әгъзаларына яки бүлекчәләренә, Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән затларның якын туганнарының фикерләрен исәпкә алу максатларында, Нигезләмәнең 2.5 пунктында каралган исем бирү юлы белән аларның истәлеген мәңгеләштерү мөмкинлеге турында Нигезләмәнең 3.5.1 пункты нигезендә акт белән расланган тәртиптә оештыру, тикшерү яки башка кирәкле чараларны үткәрү турында йөкләмә бирә.

3.5.6. Комиссия муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирелү аеруча әһәмиятле булган очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына, законда каралган формаларда, Зеленодольск муниципаль районы халкының җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү буенча чаралар үткәрү турында тәкъдим кертә ала.

3.5.7. Кергән документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия бәяләмәләрне рәсмиләштерә һәм, барлык материалларны да кушып, Башкарма комитетка Комиссиянең йомгаклау утырышы узган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

Карарлар (боерыклар) чыгарылганда, Комиссия бәяләмәләре исәпкә алынырга тиеш. Комиссия бәяләмәсендәге нәтиҗәләр карарлар (күрсәтмәләр) чыгарганда мәҗбүри булмый.

3.6. Муниципаль предприятиегә яисә учреждениегә исем бирү мөмкинлеге турында Комиссия карар кабул иткән очракта, Башкарма комитетка аңлатма язуы; Комиссия бәяләмәсе,, Комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтәләр Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документлар кушымталары белән тапшырыла торган карар проекты әзерләнә.

3.7. Комиссия тарафыннан муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү өчен нигезләрнең булмавы һәм шул ук вакытта инициатор тарафыннан каршылыклар булмау турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет җитәкчесенә, Комиссия бәяләмәсен кушып, күрсәтмә проекты тапшырыла.

3.8. Инициаторлар Комиссиянең муниципаль предприятиегә яки учреждениегә исем бирү өчен нигезләрнең булмавы турындагы карары белән риза булмаган очракта, Башкарма комитет җитәкчесенә Нигезләмәнең 3.6, 3.7 пунктларында күрсәтелгән документлар белән инициаторның каршы килүе язма рәвештә (ирекле формада) тапшырыла.

3.9. Карар (күрсәтмә) Башкарма комитетта гаризаны (үтенечнамәне) теркәгән көннән алып 30 календарь көннән дә артмаган срокта кабул ителә (имзалана).

Нигезләмәнең 3.5.6 пунктында каралган чаралар үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән срок 15 календарь көнгә озайтылырга мөмкин.

3.10. Карар кабул ителгән очракта Башкарма комитет 3 эш көне эчендә инициаторга кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә.

Шул ук сорау буенча кабат гариза (үтенечнамә) белән инициатор Башкарма комитетка 5 елдан да иртәрәк мөрәҗәгать итәргә хокуклы түгел.

## 4. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү турында муниципаль хокукый актларны гамәлгә ашыру. Хокук куллану практикасында барлыкка килгән бәхәсләрне һәм каршылыкларны көйләү.

4.1. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә исемнәр бирү чараларына чыгымнар, Нигезләмәнең 1.7 пункты белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, законнар белән тыелмаган башка чыганаклардан, муниципаль берәмлек бюджеты, юридик затлар, оешмалар һәм башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4.2. Нигезләмәне үтәгәндә барлыкка килергә мөмкин бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр юлы белән яисә законда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.